ӘМИНӘ БИКЧӘНТӘЕВА

Яз шатлыгы





ӘМИНӘ БИКЧӘНТӘЕВА

ЯЗ шатлыгы



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2003

Умырзая

Умырзая чәчәге
Бар чәчәктән уздырып,
Җир өстенә калыккан,
Кар мендәрен туздырып.

— Ай, нинди матур! — дидек,
Умырзаяны күреп.
— Яз бүләге безгә, — дип,
Зөлфия тора көлеп.

Энҗе чәчәк

Яшел яфрак эченә
Энҗе чуклар эленгән,
Аңкып тора хуш исе,
Ничек үсеп өлгергән?

Килеп керсәң урманга,
Аның исен тоясың,
Рәхәтләнеп иснәгәч,
Иркен сулап куясың.

Көнбагышлар

Сары эшләпә киеп
Утыралар үзләре,
Гел кояшка караганга,
Кояш төсле йөзләре.

Яз шатлыгы

Алмагачлар алсуланып чәчәк ата,
Тәмле хуш ис аңкып тора болыннарда,
Куе булып яшел чирәм үсеп тора,
Рәхәт була уйнап йөргән колыннарга.

Сусыл чирәм тәмле була сыерларга,
Бик мул итеп сөт бирәләр алар безгә.
Яшел уҗым бизәп тора иген кырын,
Бу зур шатлык, якты өмет һәммәбезгә.

Беренче пароход

Кыш буе зарыгып көттем мин
Беренче пароход килгәнен,
Яратам капитан абыйның
Туктарга команда биргәнен.

Кул изим капитан абыйга,
Елмая ул мине күргә,
Мин дә бит бик телим, зур үскәч,
Аның күк ил гизеп йөрергә.

Инеш



Йомшак сулы инеш буе
Тып-тын торды кыш буе,
Язлар җиткәч, хәзер анда
Гөрли балалар туе.

Балык та бар суында,
Тота белсәң, тотасың,
Майга салып кыздырсаң,
Телләреңне йотарсың!

Каз бәбкәләре

Һәммәсе дә бер төрдән
Сары күлмәк кигәннәр,
Әниләренә ияреп,
Су буена килгәннәр.

Кайтып китми бер бәбкә дә
Ялгыз гына өенә,
«Йөзәргә өйрәнделәр», — ди
Әниләре сөенә.

Беренче яңгыр

Чыгыгыз урамга, нәниләр,
Беренче яңгырны күрегез.
— Мин үсәм, яңгырда үсәм, — д
Кинәнеп, яланбаш йөрегез!

Яңгыр, яу, яу әйдә, гөрелдәп —
Чиләкләр тулсыннар мөлдерә
Бөтен җир тузаннан арчылсы
Яшәреп бөреләр ачылсын!
Ул яугач, игеннәр мул булсын

Каен җиләг

— Куе үләннән
Эзләп табыгыз,
Тизрәк авызга
Алып кабыгыз.

Минем исемем —
Каен җиләге,
Җиләкләрнең дә
Менә дигәне.

Карлыгач баласы

Җиргә төшкән егылып
Карлыгачның баласы.
Җим эзләргә, күрәсең,
Очып киткән анасы.

— Бик матур икән күзең,
Тыңла әниең сүзен,
Әниең юк чагында
Очып йөрмә берүзең.

Бераз шулай үгетләп,
Оясына менгердек,
Кайтып җитте анасы,
Без тиз генә йөгердек.



Колын

Иркен яшел болында
Чабасың да чабасың,
Син яшь кенә бит әле,
Аякларың талмасын!

— Юк, сез алай димәгез,
Көчем арта күп чапсам,
Ничек мин зур үсәрмен,
Көн буена тик ятсам.



Нәни каен

Җирдән яңа калкып чыкка
Ул әле бала каен.
Бераз үскәч, чып-чын каен
Булыр ул, балакаем!

Март аенда

Челтәрләнгән боз өстенә
Кояш елмаеп карый.
Һәрбер көнен саный-саный
Язны күтәргә ярый.

Кар дип җиргә басасың,
Суга кереп батасың,
Чыксын инде умырзая,
Кар астында ятмасын.

Апрель ае

Апрель ае шук икән,
Бөтен карны юк иткән,
— Мин килдем, — дип әйткән ика
Бозлар аккан да киткән.
Менә ул нинди икән!

Кара карга

Кара әле, дустым, кара,
Кара карга очып бара,
Син беләсеңме, Гөлсара,
Ул да бит сөйләшә ала.

Ишетәмсең: — Кар да кар! — ди, —
Тиздән эреп бетә кар, — ди, —
Канатымда хатым бар, — ди, —
Буең җитсә, тартып ал, — ди.

Укымый да беләбез бит
Хатында ни язылганын,
Бөтен кошлар хәбәр иткән
Матур язны сагынганын.

Сыерчыклар

Сыерчыклар «чык-чык!» дип
Чакыргач чыктым әле,
Мин аларның дусты бит,
Мин әнинең Дилбәре.

Абау, җаным, күр әле,
Нәни генә үзләре,
«Чик-чирик!» та, «чык-чык!» икән
Бөтен белгән сүзләре.

Безне бик дус итәләр,
Кортларны юк итәләр,
«Чик-чирик!» дип кайталар да
«Чик-чирик!» дип китәләр.

Карлыгач

Көннәр бераз җылыгач та,
Күксел-кара күлмәк киеп,
Очып килде карлыгач та,
Язлар инде җиткән, диеп.

Балаларын чыгарырга
Тыныч, матур оя корды,
Җитезлектә карлыгачым
Бөтен кошлардан уздырды.





Күз алмыйча карап тордык
Җил-җил очып килгән чагын,
Балаларын очырткanын
Күрми генә калмыйк тагын!

Тургай

Ай-һай, тургай, биек менгәнсе
Югарыдан безне күрәмсең,
Без бит сине өзелеп сагындык
Тавышыңнан бик тиз таныды

Ялтыраса кояш нурлары,
Син уйнасаң күктә югары,
Без куанып куллар чабабыз,
Язны бергә каршы алабыз.

Менә нинди күңелле!

Бүген төнлә яңгыр яуган,
Кырлар яшәреп калган,
Нинди күңелле булган,
Уйсуларга су тулган.

Каз-үрдәкләр коена
Җылы яңгыр суында,
Без уйныйбыз рәхәтләнеп
Яңгырдан соң болында.

Абыйлар һәм апалар —
Һәммәсе дә куанган,
Гел бер сүзне әйтәләр:
— Һай, әйбәт яңгыр яуган.

Яз көнендә базарда

Әнием белән икәү
Базарга киттек иртән,
Яз көнендә базарда
Күңелле була икән.

Колхозчылар безгә дип
Үстергәннәр барын да:
Суганын да, кыярын да,
Китергәннәр балын да.

Җил сөйләшә беләме?

— Әнием, җил сөйли, дисең,
Ул сөйләшә беләмени?
Җил ишектән керә, дисең,
Тәпи йөри беләмени?

— Сөйләштерә белсәң, балам,
Агачлар да телгә килә,
Ак каенга сәлам бирсәң,
Әкрен генә башын ия.

Җил сөйләшә, тик син аңа
Серләреңне сөйли күрмә,
Җил йөгерә, тик син, аннан
Калышмыйм дип, тиккә йөрмә.

Фермада

Бик өйрәнәсем килә
Йөзгә кадәр санарга,
Йөзләп чеби уртасында
Белмим кая карарга.

— Әй, чебиләр, чебиләр,
Тезелешеп янымда
Торыгыз әле бераз,
Мин санаган чагында.

Мин санарга өйрәнәм ич,
Ә сез шуны белмисез,
Бер минут та тик тормыйсыз,
Йөрисез дә йөрисез.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бик күп анда чебиләр,
Бишәү, алтау, җиде, сигез,
Үсә барысы бертигез.

Бәтиләр

Үсә безнең фермада
Бик күп нәни бәтиләр.
— Бә! — диләр, — бә! — диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.

— Ничек исемнәрегез? —
Дип сорагач, бәтиләр:
— Бә! — диләр, — бә! — диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.

— Сезгә ничә яшь? — дигәч,
Аңламыйлар бәтиләр,
— Бә! — диләр, — бә! — диләр,
Башка берни әйтмиләр.

— Шәл бәйләргә йон безгә
Бирегезче, бәтиләр!
— Мә! — диләр, — мә! — диләр
Бөдрә тунлы бәтиләр.

Очрады ул миңа болында



Күз алдымда тора һаман да
Кызыл күлмәк кигән кыз бала,
Очрады ул миңа болында,
Озын чыбык иде кулында.

Үләннәрдә чык та кипмәгән,
Тып-тын иде бөтен тирә-юнь,
Мин ишеттем бу кыз баланың
Казларына нидер сөйләвен.

Бер көтү каз иде алдында,
Озын чыбык иде кулында,
Ак яулыклы нәни кыз бала
Очрады ул миңа болында.

Балык тотканда

Беренче тапкыр Фәрит
Кулына кармак алды,
Абыйсы белән бергә
Балык тотарга барды.

Суда балык күптер дә,
Эләкми бит берсе дә,
Тота алмаса, көләр инде
Кечкенә сеңелесе дә.

Менә бәхет, эләкте
Нәни кортыш бер балык,
— Песиемә күчтәнәч, — дип,
Куйды кәрҗингә салып.

Көтү чыккач

Көтү чыкты бүген, көтү чыкты
Кунак булып урман буена,
Мөгериләр әнә сыерлар да,
Рәхмәт әйтеп язның сыена.

Без дә шунда урман буенда
Кичкә кадәр бүген уйнадык,
Сыерлар да инде ашап туйды,
Тик без генә уйнап туймадык.

Нәсимә һәм күгәрчен

Мөлдерәтеп чиләгенә
Су алганда Нәсимә,
Очып төште кук күгәрчен
Чиләге тирәсенә.

Сусагандыр ул, күрәсең,
Канатлары талгандыр,
Бәлки әле очалмыйча
Дусларыннан калгандыр.

Бик тиз аңлады Нәсимә
Аңа нәрсә кирәген,

Җиргә бераз су салды да
Читкә алды чиләген.

— Эч, кадерле күгәрченем,
Балдай татлы суыбыз,
Ерак булганда юлыгыз,
Бездә кунак булыгыз.

Күгәрченкәй рәхәтләнеп
Су тамчылары эчте,
Аннан җилпеп канатларын,
Ерак юлларга очты.

Йокла инде, курчагым

Зәңгәр күзле курчагым,
Әлли-бәлли ит әле,
Синең бит йоклар чагың,
Тәмләп йоклап кит әле.

Мин әнигә булыштым,
Сулар сиптем гөлләргә,
Мин барсына өлгерәм,
Синең белән йөргәнгә.

Арыгансыңдыр, курчагым,
Йокла инде, йом күзең,
Синең яныңа ятып
Йоклап китәм мин үзем.

Кызыл шарым

Кызыл шарым, җиңел шарым,
Бик яратам сине, җаным,
Оч, биеккә күтәрел син,
Әтием алыр әле тагын.

Арада иң матуры дип,
Бик яратып сайлап алдым
Бөек бәйрәм — Майны кот
Оч югары, кызыл шарым.

Парадта

Өйдә мине әтием дә,
Әнием дә сөяләр,
Син бит безнең зур улыбı
Үстең инде, дияләр.

Шулай дигәч, мин үземне
Зур диеп белгән идем,
Үстем инде хәзер, диеп
Куанып йөргән идем.

Менә бәйрәм иртәсендә
Чыктым парад күрергә,
Бәйрәм итеп, рәхәтләнеп,
Зурлар белән йөрергә.

Бераз баргач алар белән
Шундый ардым, тирләде
Ә шулай да берсенә дә:
— Уф, ардым мин! — дим

Минем бакчам

Иркен дә һәм матур да
Безнең туган илебез,
Урманга бай, суга бай
Гөлбакчалы җиребез.

Мин дә бакча үстерәм
Өебезнең түрендә,
Иптәшләрем киләләр
Бакчабызны күрергә.

Эштән кайткач әнием
Ял итә шунда кереп,
Ул куана алсу чәчәк
Аткан гөлемне күреп.

Актүш

Ап-ак, тузгак, түгәрәк,
Туп шикелле тәгәрәп,
Шаярганда идәндә,
Бик матур ул сөяргә.

Берәү килеп кагылса
Кинәт кенә ишеккә,
Хәзер башлый өрергә,
Бигрәк тә тиз ишетә.

Минем әнием

Мине әнием көн саен
Бакчага үзе илтә,
Мин бакчада уйнап калам,
Әнием эшкә китә.

Оста тегүче булып
Танылган ул эшендә,
Аның теккән киеме
Бик килешә кешегә.



Матур кием киярга
Без дә бит бик сөябез,
— Рәхмәт моны тегүче
Апаларга, — диябез.

Нәни чакта һәм зур үскәч

Бик яраткан гөлләрне
Нәни чакта Гөләндәм,
Хәзер күзләр камаша
Ул үстергән гөлләрдән.

Нәни чакта Айтуган
Чанада гына шуган,
Хәзер батыр йөрәкле,
Данлы очучы булган.

Алмагачлар, чияләрне
Яшьтән сөйгән Кәбирә,
Данлы бакчачы хәзер
Илгә җимешләр бирә.

Кечкенәдән машиналар
Ясап уйнаган Рөстәм,
Укыган да тырышып,
Инженер булып үскән.

Врач булып уйнаган
Нәни чакта Гөлбикә,
Хәзер өлкән врач ул,
Халыкка хезмәт итә.

Урамдагы суларда
Көймә йөздергән Марат.
Хәзер инде корабта
Диңгез гизүче моряк.

Курчак уйнаганда

Нинди матур, күрәсезме, курчак өем,
Җыеп куйдым аны чиста, пөхтә итеп.
Курчакларны бик матурлап тезеп куйгач,
Песием дә карап тора исе китеп.

Бу курчагым — очучы кыз, бик яратып,
Аңар үзем Таня дигән исем бирдем.
Менә монысын миңа әни тегеп бирде,
Исеме аның була инде Гөлсем, дидем.

Ә менә бу комбинезон кигән курчак —
Зур заводта эшли торган эшче инде,
Нәни апам мине бик-бик ярактанга,
Миңа шундый әйбәт курчак ясап бирде.

Ә менә бу — ак халатлы, күзлеклесе —
Врач апа, дару бирә авырганда.
Ә менә бу зур курчагым — физкультурник,
Шуңа күрә көчләрәк ул барыннан да.

Бу курчагым — укытучы, нинди әйбәт.
Балаларны ярата ул, якын күрә,
Бик тырышып укыта ул дәресләрне,
Балалар да әйбәт укый шуңар күрә.

Күрәсезме, монысы кызыл галстуклы, —
Пионер бу, үзе укый бишкә генә,
Ул бит курчак, чын отличник үзем булам,
Җиде тулсын, мин хәзергә биштә генә.

Бик рәхмәт, кызларым

Фәридә, Зөбәйдә
Бакчага баралар,
Алар бик акыллы,
Тәртипле балалар.

Бу кызлар бер сукыр
Әбине күрәләр,
Тиз генә йөгереп,
Янына киләләр.

— Тукта әле, әбекәй,
Таптала күрмә син,
Җитәклик үзеңне,
Ялгызың йөрмә син.

Бу сукыр әбине
Җитәкләп кулыннан,
Чыгарды ике дус
Трамвай юлыннан.

Һәм юлны өйрәтеп
Киттеләр аңарга,
— Бик рәхмәт, кызларым, —
Ди әби аларга.

Гөлсем апа

Гөлсем апаны күрерсез,
Бакчабызга килсәгез,
— Менә безнең тәрбияче —
Гөлсем апа, — диярбез.

— Кайнамаган салкын суны
Эчмәгез! — ди ул безгә,
Аның сүзен онытмыйбыз
Кайткач та өебезгә.



— Үскәннәрем, — ди ул безгә, —
Чиста булсын сөлгегез,
Бервакытта да авыртмас
Сезнең матур күзегез.

Порошок белән юабыз
Тешебезне агартып,
— Шикәр төсле булган ич, — ди
Гөлсем апа яратып.

Дус кызлар

Гөлгенә, акыллым,
Иртән үк торгансың,
Күр нинди ап-ак син,
Бит-кулың югансың.

Сәгатьтән бер минут
Күзеңне алмыйсың.
Һәр минут үтүгә,
Сәгатькә карыйсың.

Нигә син куандың,
Әйт але, Гөлгенә?
Күзең дә, йөзең дә
Шатлыклы күренә.

Уйнарга курчаклар
Алдымы әтиең?
Үзеңә күлмәкләр
Тектеме әниең?

Шатланып, куанып
Тордыңмы, матурым?
Сөйләче барын да
Син миңа, акыллым!

— Юк, апа, мин хәзер
Курчаклар уйнамыйм.
«Тәтиләр кирәк!» — дип
Мин хәзер еламыйм.

Беренче мәртәбә
Мин барам мәктәпкә,
Отличнo укучы
Булырмын, әлбәттә.

* * *

Йөгереп керде дә
Дус кызы Миләүшә,
Гөлкәйне мәктәпкә
Барырга эндәшә.

Гөлгенә тиз генә
Өстенә киенде,
«Укырга бара!» — дип,
Әнисе сөенде.

Гөлгенә, Миләүшә
Киттеләр икәүләп,
Әнисе аларны
Озатты иркәләп.



Дус кызлар әйтерсең
Түгәрәк пар алма,
Аларның баруын
Күңелле карарга.

Баралар гөрләшеп,
Ике дус сөйләшеп,
Отлично укучы
Булырга киңәшеп.

Әлифбам

Китап магазинына
Әтием белән барып,
Матур тышлы, өр-яңа
Әлифба сатып алдык.

Ачып карагач аны,
Мин шатландым тагын да,
Андагы хәрефләрнең
Мин белермен барын да.

Сумкага салып аны,
Мин мәктәпкә барырмын,
Дөрес итеп сүзләрен
Тиздән укый алырмын.

Рәсеме дә күп аның,
Кызык үзе карарга.
Чиста саклармын аны,
Яңа торыр һаман да.

Күп нәрсәләр белермен
Туган илем турында,
Өйрәнермен укырга,
Әлифбам бар кулымда.

Кырык туган

Абыем һәм энем белән
Өчебез бертуган без,
Бик күңелле бергә-бергә,
Бик бәхетле торабыз.

Ә быел укырга кергәч,
Булды кырык туганым,
Туганнарым күбәйгәчтен,
Бик тә, бик тә куандым.

Яшькә түгел, буйга бераз
Дусларымнан калышам,
Ә укуга мин алардан
Бер адым да калышмам.

Җиде тулгач һәммәбезгә,
Без кергәнбез укырга.
Укысак та, уйнасак та,
Кирәк гел дус булырга.

Язарга өйрәнгәндә

Мин бит хәзер зур инде,
Укып йөрим мәктәптә!
Яза да беләм инде,
Акыллы да, әйбәт тә!

Без бик күп бер класста,
Тату уйныйбыз бергә,
Укытучыбыз өйрәтә
Язу яза белергә.

Дөрес итеп утырып,
Язам җайлап, матурлап,
Ярамый бит дәфтәргә
Төшерергә кара тап.

Апа әйтә: хәрефләр
Тигез генә язылсын,
Синең язган язуны
Бар кеше дә танысын.

Үрли дә үрли генә

Рәис белән Хәдичә
Ялгыз калдылар кичә,
Уйнадылар ут белән,
Ни буласын белмичә.

Мич алдында чырага
Рәис утны элдерде,
Ялкын кинәт чырадан
Күлмәгенә үрелде.

Ул бит берни дә белми,
Үрли дә үрли генә,
Әниләре, ичмасам,
Керми дә керми генә.

Нишләргә дә белмиләр,
Рәиснең тәне пешә,
Ярый, югары өйдән,
Бәхеткә, апа төшә.

Апа утны сүндерә,
Коткарырга өлгерә,
Рәис үзе исән калды,
Янды күлмәге генә.

Дүртьюллыклар

* * *

Чәнчә бармак кадәр иде
Утыртканда гөлгенәм,
Хәзер инде тармакланып,
Түшәмгә кадәр менгән.

* * *

Рәхмәт инде әтигә,
Мине дә эшкә өйрәтә:
— Бүрәнәгә утыр, улым,
Без кискәндә, — дип әйтә.

* * *

Кыш көнендә ап-ак карга
Төренгән иде урман,
Хәзер яшел күлмәк кигән,
Чәчәкләр белән тулган.

* * *

Шомыртлар чәчәк атканда,
Урманда ямьле була,
Көз җиткәндә, шомыртлары
Ашарга тәмле була.

* * *

Шаярганга ут белән
Ачуланды әбисе,
Рәхмәт әйтте апасына,
Коткарганга Рәисне.

Гөлбикә

Карлар эреп беткәнне
Күрми калган Гөлбикә,
Калын шәлен бөркәнеп,
Чана шуарга китә.

Тыңламады анасын,
Тартып китте чанасын,
Белмәде ни буласын,
Көлке булып каласын.

Чана шуган тауларда
Юк инде бала-чага,
Ялтырап кояш нурында
Кар суы гөрләп ага.

Тирләп беткән Гөлбикә
Шәлен салып ташлады,
Чанасына утырды да
Үксеп елый башлады.

Әй Гөлбикә, Гөлбикә,
Язлар үткәч, җәй җитәр,
Еласаң күрми калырсың,
Җәйләр дә үтеп китәр.

Әлфия алъяпкычлары

Безнең күрше Әлфия
Матурлыкны бик сөя,
Матур булмаган киемне
Үзе матурлап кия.

Үзе юып, тегеп куя
Күлмәгенә якасын,
— Тегеп бирче син генә! — дип,
Аптыратмый апасын.

Алъяпкычлары үзенә
Килештереп тегелгән,
Иңбашлары канат кебек,
Матур итеп бөрелгән.

Тегелүен тегелгән дә,
Бөрелүен бөрелгән,
Тик аларның берсен-берсе
Җәберлисен кем белгән?

* * *

Беркөн шулай ак алъяпкыч
Масаеп сүз башлады.
Дусты кара алъяпкычны
Мыскыл итеп ташлады.

— Кара алъяпкыч, син, — диде, —
Тик таушалып йөрисең,
Бәйрәмнәрдә бик күңелле
Кичәләрне күрмисең.

Әлфия мине юа да,
Ап-ак итеп агартып,
Бәйрәм көннәрендә яба:
— Аппагым! — дип яратып.

Мәктәпкә баргач үзенә
Кара таплары тия,
Мине яба биегәндә
«Әпипә»гә Әлфия.

Әлфия гел мине мактый,
Кадерләп кенә саклый,
Мине генә ярата шул,
Сине бер дә яратмый.

* * *

Кара алъяпкыч хурланды,
Үкси-үкси елады,
Әлфия бер читтән генә
Исе китеп тыңлады.

Менә ул ак алъяпкычын
Читкә этеп куйды да
Кара сатин алъяпкычны
Алды назлап кулына.

— Кара матур алъяпкычым,
Сине яратып ябам,
Синең белән бишләр алам,
Куанам, шатлык табам.

Ак алъяпкыч хурлаганга,
Һич калмасын хәтерең,
Тырыш кызлар яхшы белә
Кара алъяпкыч кадерен.

Сине дә мин һичвакытта
Былчыракка буямыйм,
Тидермәмен кара тап та,
Хур итәргә уйламыйм.

Сине ябып һәр көн саен
Мин мәктәпкә бармасам,
Язга кадәр, бик тырышып,
Укып белем алмасам,

Миңа оят булмасмы соң,
Язның матур көнендә,
Алъяпкычым ак кына дип,
Күңел ачып йөрергә.

4

Әлфия шулай дигәнгә,
Кара алъяпкыч юанды,
Мин дә кирәк Әлфиягә,
Ярата, дип куанды.

Ак алъяпкыч Әлфиядән
Бик оялды, үкенде,
Дусты кара алъяпкычтан:
— Гафу ит! — дип үтенде.

Ышанмасагыз бу хәлгә,
Сорагыз Әлфиядән,
Ул үзенең мәктәптәге
Дусларына сөйләгән.

Эчтәлек

Умырзая 2
Энҗе чәчәк 2
Көнбагышлар 2
Яз шатлыгы 2
Беренче пароход 3
Инеш 3
Каз бәбкәләре 4
Беренче яңгыр 4
Каен җиләге 4
Карлыгач баласы 5
Колын 5
Нәни каен 6
Март аенда 6
Апрель ае 6
Кара карга 6
Сыерчыклар 7
Карлыгач 7
Тургай 8
Менә нинди күңелле! 8
Яз көнендә базарда 9
Җил сөйләшә беләме? 9
Фермада 10
Бәтиләр 10
Очрады ул миңа болында 11
Балык тотканда 11
Көтү чыккач 12
Нәсимә һәм күгәрчен 12
Йокла инде, курчагым 13
Кызыл шарым 13
Парадта 14
Минем бакчам 14
Актүш 15
Минем әнием 15
Нәни чакта һәм зур үскәч 16
Курчак уйнаганда 17
Бик рәхмәт, кызларым 18
Гөлсем апа 18
Дус кызлар 19
Әлифбам 21
Кырык туган 22
Язарга өйрәнгәндә 23
Үрли дә үрли генә 23
Дүртъюллыклар 24
Гөлбикә 25
Әлфия алъяпкычлары 26

УДК 820/89(470)
ББК 84(2 Рос-Тат)-5
Б 49

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Рәссамы ИЛДУС ӘҖЕМОВ

Бикчәнтәева Әминә

Б 49 Яз шатлыгы: Шигырьләр. — Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. — 32 бит.

Әминә Бикчәнтәеваның нәниләр өчен язган иң матур шигырьләрен туплаган бу җыентык шагыйрәнең 90 еллык юбилее уңае белән нәшер ителә.

ISBN 5-298-01296-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2003

Литературное издание для детей

Бикчентаева Амина Ахметовна

РАДОСТЬ ВЕСНЫ

(на татарском языке)

Төзүчесе һәм мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 6.05.2003.
Форматы 60×90[1]/8. Офсет кәгазе. «ТатCooper» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 4,0. Шартлы-буяу оттиск 18,0. Нәшер-хисап табагы 4,58.
Тиражы 3000. Заказ Я-234.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.